**Класс:** 5

**Укытучы:** Шакирова Рузилә Рәисовна

**Программа:** Вигасин А.А. Гомуми тарих. Борынгы заман тарихы. 5 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / - Казан: Татар.кит. нәшр., 2020.

**Тема:** Һиндстанда касталар

**Максаты**: Һиндстанда касталар барлыкка килүне өйрәнү; укучыларны касталар тормышы белән таныштыру; укучыларда тарих фәненә кызыксыну тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗә:** карта белән эш, яңа терминнарны үзләштерү.

I **лекция**

**Исәнмесез укучылар! Бүгенге тема Һиндстанга багышлана.**

**План (2 слайд)**

- Дүрт кастаның килеп чыгышы турында миф
- Брахманнарның корбан китерүе
- Брахманның тормыш юлы
- Атаклы сугышчылар, игенчеләр һәм хезмәтчеләр касталары

Дүрт кастаның килеп чыгышы турында миф. **Укучылар, әйдәгез, һәр каста нәрсә аңлатканын карап китик**. **(3 слайд)** Һәр Һиндлы туган көненнән үк дүрт кастаның берсенә: каһиннәргә, атаклы сугышчыларга, игенчеләргә һәм хәзмәтчеләргә караган. Һиндлылар һәр каста Брахма алланың кайсы да булса бер өлешеннән яралган дип уйлаганнар. **(4 слайд) Каһин – брахманнар** аның авызыннан яралган, шуңа күрә доганы ничек укырга икәнен беләләр. **Сугышчылар (кшатрии)** Брахманың көчле кулларыннан килеп чыкканнар, шунлыктан яхшы сугышалар. Раҗалар (патшалар), гадәттә, шушы кастадан килеп чыканнар. Халыкның күпчелеге – **игенчеләр (вайшьи),** терлекчеләр –

Брахма алланың ботларыннан барлыкка килгәннәр. Ә **хезмәтчеләр (шудры)** барысыннан да түбән катлау, чөнки алар Брахманның тузанланып беткән аяк табаннарыннан яралганнар. Һәр кастаның үз төсе булган: **ак** - каһиннар, **кызыл** - сугышчылар, **сары** – игенчеләр, **кара** хезмәтчеләрнеке булган. **“Кагылгысызлар”** бер кастага да кермәгәннәр.

**(5 слайд)** Һиндылар исәпләвенчә, төрле каста кешеләре, төрле токымдагы хайваннар кебек үк, тумышлары белән бер-берсеннән аерылып торган. Ата-анасы игенче булган кеше беркайчан каһин дә, атаклы сугышчы да була алмаган. Сыердан, мәсәлән, колын яисә дуңгыз баласы тумый бит. Брахман балалары, үскәч, каһиннәргә, ә хәзмәтчеләрнеке хәзмәтчеләргә әверелгәннәр.

**Һиндстанда иң акыллы һәм абруйлы кешеләр булып кемнәр саналган соң?(6 слайд)** Әйе, брахманнар саналган. Аларны аллаларга корбан китерергә теләгән һәр йортка кунакка дәшкәннәр. Йорт хуҗасы моның өчен аларга зиннәтле бүләк әзерләгән. Гадәттә, сыер бирергә тәкъдим иткән. Корбан чалганда, брахманнар башта ике таякны бер-берсенә ышкып ут чыгарганнар. **(7 слайд)** Һиндлылар дөге һәм арпа, май һәм сөт корбан учагында янмый, төтен белән күккә, аллалар янына оча дип уйлаганнар. Аллалар тук һәм канәгать булсалар, рәхмәт йөзеннән яңгыр яудырганнар, кырларда мул булып игеннәр уңган. Кешеләр һәм аллалар менә шулай бер-берсен тукландырган.

**(8 слайд)** Брахман тормышы берничә чорга бүленгән: белем алу, гаилә кору һәм дәрвишлек. Каһиннар аллаларга нинди сүзләр белән мөрәҗәгать итәргә, аларны ничек сыйларга һәм ничек олыларга икәнен белергә тиеш булганнар. Брахманнар бу гыйлемне бик тырышып һәм озаклап өйрәнгән. Гадәттә, брахман үзенең улын, җиде яше тулгач, укырга биргән. **(9 слайд)** Ул аны укытучы - брахманның өенә китергән

һәм анда яшәргә калдырган. **Монда баланы нәрсә көткән соң?** Малай укытучысын тыңларга һәм аны, ата-анасы шикелле күреп, ихтирам итәргә тиеш булган. **(10 слайд)** Укытучыга арка белән борылу рөхсәт ителмәгән. Аның янына бары тик яланбаш һәм аяк киемсез генә килергә мөмкин булган: исәнләшкәндә, укучылар укытучының аякларына тигәнче башларын игәннәр. Алар укытучының һәр әйткән сүзен кабатлап, китапка язылган һәр җөмләне ятлап барырга тырышканнар. Укытучының йорт эшләрен дә алар эшләгән – кояш чыккanda торып, төрле эшләр башкарганнар: учак якканнар, сыерларын көткәннәр. Малай уналты яшенә җиткәч, ата-анасы аның укытучысына сыер бүләк иткән, ә аңа кәләш эзләгән.

**(11 слайд)** Белем алгач һәм өйләнгәч, брахман үзе дә укытучылык итүгә, кешеләр һәм үзе өчен аллаларга корбан китерүгә хокук алган. Оныклары тугач, чәчләренә чал төшкәч, брахман, йортын өлкән улына калдырып, үзе дәрвиш булып киткән. **(12 слайд)** Дәрвиш - башкалар белән аралашудан ваз кичеп, ялгызы гына яшәүче кеше. Ул, күңел тынычлыгына ирешү өчен, кешеләрдән читтә - урманнарда яшәгән, коры җиргә ятып йоклаган, урман җимешләре белән генә тукланган. Кайбер дәрвишләр үзләрен авыр җәфаларга дучар иткәннәр: ач торганнар, еллар буе сөйләшмәгәннәр. Алар шушы газаплардан соң теге дөньяда үзләренә җиңеллек килер яисә яңадан брахман булып туарлар, хәтта аллалар белән бергә күктә үк яшәрләр, дип ышанганнар.

**Әйдәгез, сугышчылар кастасы тормышы турында сөйләшик**. **(13 слайд)** Һинд патшалары атаклы сугышчылар кастасыннан булганнар, үз тирәләренә дә шушы каста кешеләрен якынайтканнар. Сугышчылар филләр яки зур тәгәрмәчле арбаларга утырып сугышларда катнашканнар, ә тыныч вакытта сарайларда мәҗлесләр оештырганнар, ауга чыканнар, җәядән ук ату ярышлары үткәргәннәр. Сугышчылар

үзләренең ата-бабалары Рама кебек борынгы патшалар һәм батырлар булган, дип исәпләгәннәр. Менә шуңа да алар гади игенчеләрдән, хезмәтчеләрдән күпкә өстен катлау булып саналганнар. **(14 слайд)** Үз йорт-җирләре, кырлары һәм терлекләре булган игенчеләр дә ярлы хезмәтчеләргә түбәнсетеп караганнар. Хезмәтче, мөлкәт туплап, аллаларга корбан китерү хокукына ия булмаган. Үз хуҗасына ул берсүзсез буйсынган һәм өстен каста кешеләрен, бигрәк тә брахманнарны хөрмәт иткән.

**(15 слайд)** Иң авыр тормышта “кагылгысызлар” дип йөртелә торган хезмәтчеләр кастасы яшәгән. “**Кагылгысызлар”ның берәр хокуклары булганмы соң?** Аларга хәтта авылларда яшәү дә тыелган. Алар авыл артындагы хәерче алачыкларда яшәгәннәр, калдык-постык белән тукланганнар. Алар белән бер табын артына утыру нинди дә булса пычрак хайван белән бергә ашау кебек саналган. “Кагылгысызлар”, ерактан күренеп торсын һәм башкалар ялгыш килеп кагылмасын өчен, махсус киемнән йөргәннәр. Алар авылга кереп урам җыештырганда, башка кара эшләрне башкарганда, кешеләр алар тирәсеннән читкәрәк китәргә, гомумән, бу мескен затларны күрмәскә тырышканнар.

**(16 слайд)** Әгәр түбән каста кешесе брахманга кул күтәрсә, патша аның уң кулын кисәргә боерган. Брахманга акыл өйрәтергә җөрьәт итүченең телен кызган тимер белән тишкәннәр яки тамагына кайнар май агызганнар. Дин кешеләргә бер генә юаныч биргән, имеш, гади игенчеләр һәм хезмәтчеләр үз язмышларыннан канәгать булып, карусыз яшәсәләр, теге дөньяга киткәч, яңадан сугышчылар, патшалар һәм хәтта брахманнар булып җиргә туарга мөмкиннәр.

**(17 слайд)** Әмма кайбер борынгы Һинд акыл ияләре каста аерымлыкларына әллә ни зур әһәмият бирмәгәннәр. Мәсәлән,

буддизмга нигез салган Будда, (үз исеме Гаутама) иң мөһиме – шәхеснең кешелек дәрәҗәсе, ә килеп чыгышы әһәмиятле түгел, дип өйрәткән. Якынча ул б.э.к. VI һәм V гасырлар чигендә яшәгән.

**(18 слайд)** Хәзерге дөнья күп нәрсәләр белән һиндлыларга бурычлы. Бүген дә файдалана торган цифрларны һиндлылар уйлап тапкан. Шахматны шулай ук алар уйлап чыгарганнар. Шахмат тактасындагы фигуралар җәяүле сугышчылары, атлы гаскәре һәм сугыш филләре булган борынгы һиндлылар армиясен хәтерләтә.


**II практик өлеш**

**Беренче бирем.**

**Аңлатмаларны терминнарга туры китереп уклар белән җыегыз:**




**Җаваплар:**




(Уклар чиратлашып чыксыннар )

**Икенче бирем**

**Тексттан тарихи хаталарны табыгыз:**

Игенчегә кизәнгән шудраның кулын кискәннәр, ә игенче шудраны үтерсә дә, аңа җәза бирү каралмаган. Каһин, мәсәлән, байый, ә ниндидер шудра хәерчелеккә төшә алган. Кеше үзенең кастасын берничек тә үзгәртә алмаган һәм кем булып туса, шул булып үлгән.

**Җавап:**

~~(Игенчегә)~~**Брахманга** кизәнгән шудраның кулын кискәннәр, ә ~~(игенче)~~ **брахман** шудраны үтерсә дә, аңа җәза бирү каралмаган. ~~(Каһин)~~ **Шудра**, мәсәлән, байый, ә ниндидер ~~(шудра)~~ **атаклы сугышчы** хәерчелеккә төшә алган. Кеше үзенең кастасын берничек тә үзгәртә алмаган һәм кем булып туса, шул булып үлгән.

**Өченче бирем**

**Буш калган урыннарга аста күрсәтелгән сүзләрне куеп текстны языгыз:**

Күчмә халыкларга һәрвакыт яңа көтүлекләр кирәк булган, чөнки аларның төп байлыгын терлекләр тәшкил иткән. Бүгенге көндә дә Һиндстанның акча берәмлеге рупия (________) дип атала. __________ һәм көтүләр өчен кабиләләр арасында канкойгыч сугышлар да булган. Юкка гына Һиндстанга күчеп килгән арийлар телендә сугыш сүзе _______, ә кабилә башлыгы __________дигән мәгънәгә ия булмаган инде.

Сүзләр: “сыерларны саклаучы”, көтүлекләр, “сыерлар табарга омтылу” , сарык.

**Җавап:**

Күчмә халыкларга һәрвакыт яңа көтүлекләр кирәк булган, чөнки аларның төп байлыгын терлекләр тәшкил иткән. Бүгенге көндә дә Һиндстанның акча берәмлеге рупия **(сарык)** дип атала. **Көтүлекләр** һәм көтүләр өчен кабиләләр арасында канкойгыч сугышлар да булган. Юкка гына Һиндстанга күчеп килгән арийлар телендә сугыш сүзе **“сыерлар табарга омтылу”,** ә кабилә башлыгы **“сыерларны саклаучы”** дигән мәгънәгә ия булмаган инде.

**Дүртенче бирем**

**Дөрес җавапны тап:**

**Һиндстанда кайсы уйлап табу ясалган?**

1) шахмат
2) балчык тактачыклар
3) пыяла
4) сәгатьнең 60 минутка бүленүе

**Җавап:**

1) шахмат